**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮГАРЫ ПӘНӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

**№ 117** **21 ноября 2023 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 2014 елның 12 февралендәге 121 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге 2014 елның 12 февралендәге 121 номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге муниципаль хезмәте турында нигезләмәнең 9 статьясына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2) 17 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 20 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган классны чин бирү турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) белән, җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Югары Пәнәче авыл җирлеге**
**Совет рәисе** **М. Х. Туктаров**